ХӘЕРЛЕ ЮЛ!
Белгечләр эссе вакытта рульдә аеруча игътибарлы булырга киңәш итә
> 2

ЗЕЛЕНОВ МИРАСЫ
Түбән Камада республиканың шиннар сәнәгатенә нигез салган шәхесне искә алдылар
> 3

ХАЛЫК БИЮЕ
Казанда 500ләп кеше Кабан күле буендагы агач идәннәрнең ныклыгын тикшерде
> 4

СЫЙЛЫ БӘЙРӘМ
Әгерҗе районының Кадрәк авылында республикакүләм Семык узды
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 79 (28852) | Сишәмбе | 7 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ХУҖАСЫНА ФАЙДА КАЙДА?

РАЙОННАРДА ХАЛЫКТАН СӨТ ҖЫЮ БӘЯЛӘРЕ ТӨРЛЕ

Авылларда чыгасы көтүләр чыгып бетте, терлекләр болын-кырларда яшел үлән ашап кинәнә. Ашау мулдан һәм тәмле булгач, җәйге чорда сөт тә арта. Тик, ни кызганыч, аны җыю бәясе генә төшә. Шуңа күрә бу вакытларда хуҗалыклардан сөт сатып алу бәяләрендәге үзгәрешләр халыкны аеруча нык кызыксындыра. Ә аерма, чыннан да, сизелерлек. Кайсы районнарда сөт өчен түләүдә юмартлык күрсәтәләр дә, кайсыларында азга да канәгать?

vk.com

Азнакай районының «Бәрәкәт» авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы 16 авылдан сөт җыеп эшкәртә. Җитәкчесе Рәмис Сәхапов сүзләренә караганда, сөтнең бер литрына 30 сум түлиләр. Гомумән алганда, Азнакай районында уртача сөт җыю бәяләре 27–28 сум тирәсендә тирбәлә.

– Бәяләр май башыннан үзгәрде. Узган ел корылык булу сәбәпле, малларын киметүчеләр яки бөтенләй бетерүчеләр булды. Шуңа күрә сөт күләме дә кимеде. Ләкин без, югалту мөмкин кадәр азрак булсын иде, дип тырыштык. Халык терлекләрен бетермәсен өчен, азыкны чит төбәкләрдән алып кайтуны вакытында оештыра алдык. Бәясе арзан булмаса да, уртача төбәк бәясеннән артмады, – диде Рәмис Сәхапов.

Әлегә «Бәрәкәт» кооперативы Азнакай районында гына эшли. Ләкин инде күрше Баулы, Бөгелмә районнарыннан да чакырулар бар икән.

– Чөнки әлеге районнарда сөт җыю мәсьәләсендә оештыру аксый. Мөмкинлекләребезне тагын бер тапкыр карап, арттыра алсак, аларга да чыгу уебыз бар, – диде ул.

Чүпрәле районының Шланга авылында халык малны ишле тота. 5–6шар баш сыер гына асрыйлар бирердә. Тик хәтта шундый авылларда да сөтне шәхси хуҗалыклардан нибары 24 сумга җыялар. Әле бу ярыйсы бәя, моңа кадәр 17 сум да булды, ди авыл халкы.

– Районыбызда күпчелек авылларда шушы бәя куелган. Дөрес, Шәйморза авыллары тирәсендә 30 сумга да җыялар дип ишеттек. Апас районыннан килеп җыялар икән аларныкын, – ди Шәмсия Алимова. – Бездә кышын да, җәен дә шушы 24 сум йөри. Әле бу бераз артканнан соң шундый бәя. Бер ел элек 17, 18, 21 сум иде. Районда сөтне кабул итү пункты да ачтылар. Инде без шуннан соң яхшырак хак куя башламаслармы дип көткән идек. Әлегә күренми.

Шәмсия Алимова әйтүенчә, бәя арзан булса да, халыкның барысы да сөтне җыючыга гына тапшыра.

– Халык зарлана, әлбәттә, тик нәрсә эшли алабыз инде? Сөт күп, вакытында тапшырырга кирәк. Ике көтү чыкты, бездә маллар ишле. Авылыбыз район үзәгеннән ерак, көн саен каядыр барып йөрү дә уңайсыз, – диде әңгәмәдәшебез.

Буа районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ранис Габитов әйтүенчә, районда эре хуҗалыклар сөтне – 40 сумнан, шәхси хуҗалыклар уртача 30 сумнан тапшыра. Дөрес, халыктан җыелган сөтнең бер литрына 31, 32, 33 сум түләүчеләр дә бар.

– Кышын 25 сумнан түләделәр. Майда бәяләр күтәрелде. Узган ел игенчелектә хәлләр авыр булса да, районда шәхси хуҗалыкларда маллар артык кимемәде. Киресенчә, хәтта 40 башка артты, – диде идарә башлыгы.

Нурлат районының Кизләү авылы халкыннан сөтне ике кеше җыя. Литрына 29 сум түлиләр, диделәр. Халык белән аралашкач, әлеге бәядән канәгать булуларын әйттеләр. Моннан тыш, фермерлардан суынган сөтне Казанга алып китәләр икән.

– Без көн саен 900 литр сөт тапшырабыз. Литрына 32 сум түлиләр, – ди фермер Рәфис Ганиев. – Узган ел бу вакытта 23 сумнан тапшырдык. Былтыргы бәяләр белән чагыштырганда, без бик канәгать.

Узган атнада журналистлар белән очрашу вакытында районнар арасындагы сөт җыю бәяләрендәге аерма буенча Татарстанның авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров та үз фикерен белдергән иде. Аның әйтүенчә, мал күп булган хуҗалыкларда сөткә бәя дә яхшы.

– Шәхси хуҗалыклардан сөт җыю эше төрле районда төрлечә оештырылган, – дип раслады министр. – Без аларны ай саен анализлыйбыз, күзәтәбез, тик билгеле бер бәядән төшерергә ярамый, дип йогынты ясый алмыйбыз. Кооперативлар булган җирдә бу эш актив алып барыла. Терлек аз булган районнарда бу мәсьәләдә кыенрак, чөнки чыгымнар үз-үзен акламый. Кайдадыр – 80, кайдадыр 100 литр гына сөт булса, машина чыгымнары арта. Гомумән алганда, бу сезонда бәяләр начар түгел.

Ипотеканың яңасы булачак

Россиядә 5 процентлы «Сәнәгать ипотекасы» пәйда булырга мөмкин. Бу предприятиеләргә сәнәгать максатында күчемсез милек сатып алу өчен 5 процентлы кредит бирергә мөмкиннәр дигән сүз. Мәсьәләне Финанс, Икътисади үсеш министрлыклары, кайбер төбәкләр башлыклары белән бергә, 9 июньгә кадәр карарга тиеш.

Илдә «Сәнәгать ипотекасы»н башлап җибәрүне Россия Президенты Владимир Путин тәкъдим иткән. Исегезгә төшерәбез: 1 майда Премьер-министр Михаил Мишустин «Ташламалы ипотека» программасының гамәлдә булуын ел азагына кадәр озайту турында карарга кул куйды. Аны яңа йортлардан торак, шәхси йорт төзү яки җир кишәрлеге сатып алу өчен тотарга мөмкин. Шулай ук күпбалалы гаиләләр өчен ташламалы ипотека 2023 ел азагына кадәр озайтыла. Моннан тыш быел IT-белгечләр өчен ташламалы ипотека пәйда булды.

Газ кертүгә – 80 мең сум

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча, Бөек Ватан сугышы ветераннарына, күпбалалы гаиләләр, инвалидлар, инвалид балалы гаиләләргә, өйләренә газ сузу, газ җиһазлары сатып алу өчен, 80 мең сумга кадәр субсидия бирелә. Бу максатка барлыгы 195 миллион сум акча җибәреләчәк. Федераль программаларны гамәлгә ашыру буенча эш төркеменең Тукай районында узган күчмә утырышында шул хакта сүз булды.

Утырышны Дәүләт Думасы депутаты Әлфия Когогина үткәрде. «2021 ел башына Татарстанда газлаштыру 99,6 процентка җиткән иде. Шушы елның 1 августына 903 торак пунктта барлыгы 18,1 мең хуҗалыкка газ кертергә кирәк булуы ачыкланды. Россия Президенты Владимир Путин игълан иткән социаль газлаштыру программасы Татарстан өчен гадәттән тыш мөһим», – диде Когогина.

26 майга зәңгәр ягулыкка тоташу өчен 14,2 меңнән артыграк гариза тапшырылган. Республикада газлаштырып бетерү программасын гамәлгә ашыруга 7 миллиард сумнан артыграк акча каралган.

Юлда 4 баланың гомере өзелгән

Ел башыннан бирле Татарстанда балалар катнашында 151 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән. ЮХИДИ идарәсе башлыгы урынбасары Дамир Бикмөхәммәтов әйтүенчә, юллардагы аварияләрдә барлыгы 4 бала һәлак булган, 160ы җәрәхәтләнгән яки имгәнгән. Гомумән, һәр сигез авариянең берсе балалар белән бәйле. Узган елдагы белән чагыштырганда, куркыныч очраклар саны да, һәлак булучылар, зыян күрүчеләр саны да кимегән. Шул ук вакытта Дамир Бикмөхәммәтов әйтүенчә, аварияләрнең яртысы диярлек җәяүле балаларга карый.

Электр самокаты да зур куркыныч яный. Быел инде ике бала шуның аркасында имгәнгән. Самокатка бәйле барлыгы 8 куркыныч очрак теркәлгән. Идарә башлыгы урынбасары сүзләренә караганда, мондый аварияләр башлыча юл хәрәкәте кагыйдәләрен санга сукмауга яки машина юлыннан баруга бәйле.

Теманың дәвамы 2 нче биттә >

Актуаль тема

Битлексез

Татарстанда битлек кию режимы туктатыла. Авыручылар саны кимү сәбәпле, республиканың коронавируска каршы оператив штабы шундый карарга килгән. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча, Хөкүмәт карарына моңа бәйле тиешле үзгәрешләр кертелде.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстанның баш санитар табибы Марина Патяшина сүзләренчә, коронавирус белән авыручыларның тәүлеклек күрсәткече 3,5 проценттан 0,08 процентка кадәр кимегән. Бу – яхшы нәтиҗә. ОРВИ сезоны да тәгәлләнгән. Медицина хезмәткәрләре дә гадәти эш режимына күчкән.

– Соңгы 14 атна дәвамында инфекцияләр буенча авыручылар саны эпидемиологик чиктән түбәнрәк, – дип шәрехләде вазгыятьне Марина Патяшина. – Үпкә ялкынсыну белән хастаханәгә ятмыйча дәваланучылар санының кимүе дә куандыра. Бу безне пандемия дәвамында борчыган иде.

Марина Патяшина сүзләренчә, республикада коронавирусны ачыклау буенча тест нәтиҗәсе, норматив күрсәткечтән артып, 100 мең кешегә 210ны тәшкил итә. «Тесты уңай булган кешеләр саны исә 0,6 процентны гына тәшкил итә», – дип аңлатты ул.

Шушы сәбәпләр Татарстанда мәҗбүри битлек кию режимын туктатып торырга мөмкинлек биргән.

Шулай да, битлексез тормыш дип, үзеңне кайгырту һәм саклаудан туктарга ярамый, дип кисәтә оператив штаб. Сүз чир йоктыру куркынычы аеруча янаган төркемгә караган кешеләр турында бара. Бу – өлкән яшьтәгеләр, онкологик чирләре булганнар, йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан интегүчеләр, йөкле хатын-кызлар, хроник чирлеләр. Аларга җәмәгать урыннарында саклану чараларын кулланырга киңәш ителә.

Битлек кию режимы Татарстанда 2020 елның апрелендә кертелде. Аны гамәлдән чыгару турында фикер-тәкъдимнәр дә бер генә тапкыр күтәрелмәде. Әле быел май, июнь башында да кузгатылды бу мәсьәлә. Ул вакытта әлеге таләп Россиянең баш санитар табибы карары чыкканчы гамәлдә булачак дип аңлаттылар.

Гомумән алганда, Россиядә коронавирус белән авыручылар саны даими рәвештә дүртенче ай рәттән кими. Илнең дистәдән артык төбәге рәсми рәвештә битлек киюне туктатты инде.

Сүзгә-сүз

Татьяна МОСКАЛЬКОВА, Россиядә Кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил:

Безгә балаларын ялгыз тәрбияләүче әтиләрдән күп мөрәҗәгатьләр килә. Әниләр кебек алар да ана капиталын куллану, алимент мәсьәләләрендә ярдәмгә мохтаҗ. Илнең һәр төбәгендә әтиләрнең абруен арттыру, аларның хокуклары һәм бурычлары турында аңлату эше алып бару, махсус белем бирү программаларын булдыру файдалы булыр иде.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ҺӨНӘРЛӘР

SuperJob хезмәте Россиядә яшәүчеләрдән кайсы һөнәр вәкилләрен барыннан да күбрәк хөрмәт итүләре турында сораштырган.

Медицина вәкиле	30%
Укытучы, тәрбияче	9%
Хәрби	9%
Инженер	6%
Коткаручылар	4%

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 6–16 июнь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны
Ташламалы бәя **423 сум 48 тиен**
гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга
Ташламалы бәя **942 сум 18 тиен**
гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

Реклама 16+

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ИТАЛЬЯННАРДАН БАШКА НИШЛӘРБЕЗ...

Дөнья үзенең катастрофалы үсеш юлыннан баруын дәвам итә. Көнбатыш державалары Мәскәүгә каршы санкцияләрнең җиденче пакеты турында сөйләшәләр. Сүз – Россия банкларын (шул исәптән «Газпромбанк»ны да) халыкара түләүләр системасы – SWIFTтан өзү турында. Килешүгә ирешелсә, газга сум белән дә, доллар белән дә түләп булмаячак. Әлбәттә, европалылар энергия чыганакларына Россиядән бәйлелекне бетерү өчен дә тырыша. Американың Дәүләт департаменты Италиянең Eni һәм Испаниянең Repsol компанияләренә Венесуэла нефтен сатып алырга рөхсәт бирде. Кырыс санкцияләр астында бөлгенлеккә төшкән Каракаска бәхет елмаер, мөгаен. Атом-төш килешүенә ирешелмәсә да, Иран нефтеннән санкцияләрне алу мәсьәләсе дә карала, диләр. Байденның Согуд Гарәбстанына визиты да планлаштырыла. Франция Берләшкән Гарәп Әмирлекләре нефтенә өметләнә.

Әлегә санкцияләр көнбатышлыларның үзләренә дә бик каты суга. Германиянең тимер юл вокзаллары совет чорындагы шимбә электричкасын көтүчеләр белән тулган тимер юл платформаларын хәтерләтә. Немец хакимиятләре поездларга арзанлы айлык юл йөрү билетлары булдырганнар. Мотор ягулыгына бәяләр күтәрелү йөгеннән халыкны шулай коткарырга теләгәннәр. Хәзер поездга эләгү өчен физик яктан бик көчле булу һәм җитезлек таләп ителә. Евросоюз һәм АКШ санкцияләре дөньяның барлык почмакларында да хәлне кискенләштерә һәм ризасызлык тудыра. Һиндстанның Тышкы эшләр министрлыгы: «Европа үзенең проблемалары бөтен дөньяга да кагыла дип уйлаудан туктарга тиеш», – дигән белдерү ясады.

Европада һәм Америкада – Россиягә каршы икътисади сугыш игълан итүчеләрнең үзләрендә дә проблемалар йомгагы зур темплар белән зурая. Атаклы инвестор Илон Макс дөнья икътисадының үсешенә начар фараз биреп, «Тесла» хезмәткәрләрен 10 процентка кыскартачагы турында әйтүгә, акцияләре түбәнгә очты, 17 миллиард доллар югалтты. Италиянең тышкы эшләр министры Луиджи Ди Майо: «Җир шарында бөртеклеләр дефициты сәбәпле, икмәк өчен бөтендөнья сугышы бара», – дип белдерде. Ул кризисны Украина икмәген базарларга чыгара алмау сәбәпле дип саный. Сәясәтчеләр Африкада ачлык аркасында зур фетнә башланыр һәм Европага мигрантларның зур ташкыны һөҗүм итәр дип фаразлыйлар.

Италиянең Үзәк банкы җитәкчесе Игнацио Виско исә: «2,6 миллион эшсез Италиянең үсешен җитди тоткарлый», – дип белдерде. Илдә барлыгы 6 миллион эшсез бар, шуның 2,6 миллионы аңлы рәвештә эш эзләми. Бу күрсәткеч буенча Рим –Европада беренче урында. Түрәләр проблеманы мәгариф системасының начар эшләве, тиешле квалификация белән тәэмин итмәвенә китереп бәйлиләр. Илон Маск исә демографик кризиста күрә. Үткән атнада ул: «Планета итальяннарсыз калырга мөмкин», – дип белдергән иде. Узган ел Италиядә туучылар саны ил тарихында беренче тапкыр иң түбән күрсәткеч күрсәтте. Istat институты белгечләре 2070 елга итальяннар 20 процентка кимер дип саныйлар.

Россиядә

МАМЫК ФУТБОЛКАГА «БУЙ ҖИТМӘС»

Кризис барыннан да бигрәк Россиягә каты суга, билгеле. Глобаль рәвештә сиңа каршы берләшеп, санкцияләр кертәләр икән, бу гаҗәп түгел. Аркадашлар да бездән ераграк торырга тырыша бит хәзер. Казахстан нефтьчеләре элек үз нефтьләрен Россиянең Urals маркасы белән тамгалап йөртә иделәр. Хәзер аңа башка исем тагарга булдылар. Астанада, җир маен бутап, казах нефтеннән дә баш тартмасыннар дип куркалар.

Европалыларның Себер газыннан бәйлелеге россиялеләр өчен милли горурлыкка әйләнгән иде. Махсус хәрби операция башланганнан соң, Көнбатышка газ озату 2021 елның шул чоры белән чагыштырганда 29,2 процентка кимегән. Газны сумнарга сата бушлагач, кимү темплары 36,8 процентка җиткән. Май экспорты исә 39,5 процент югалткан. Ямал – Европа газүткәргече 11 майдан соң буш тора. Хәтта «төрек агымы» да өчтән бер өлешкә кимегән.

Эчке базарда да сату-алу кими. Россиялеләрнең фатир арендалау чыгымнары керемнәренең 50–70 процентына җитә дигән хәбәрләр бар. Үз түбәңне булдыру да гадәттән тыш авырлашты. Төзелеш компанияләренең зыянга эшләүләре 5,5 тапкыр артты. Үзкыйммәт зур булу сәбәпле, фатир бәяләрен төшереп булмый. Халыкара ипотека һәм күчемсез милек академиясе вице-президенты Ирина Радченко: «Төзүчеләрнең 60 проценты базардан китәргә җыена», – дип белдерә. Бу катастрофага тиң булачак. 9 процентлы өстенлекле ипотека базарны коткармый. Фатир сатып алучылар саны кискен кими. Төзелеш материалларының янына якын килә торган түгел. Базар белән таныш һәркем моны яхшы белә.

Тәм-том базарында да хәлләр шулайрак икән. Беренче дүрт айда баллы әйберләр җитештерү 3,4 процентка кимегән. Аның каравы карабодай җитештерү кискен арткан. Үсеш темпы – 36 процент.

Дөньяда мамыкка бәяләр сикерә. Һиндстанда мамык җыю бик нык кимегән. Reuters агентлыгы, җитештерүчеләр тукымага полиэстер (синтетика) куша башлаганнар, дип белдерә. Finn Flare компаниясе генераль директоры Ксения Рясова: «Мамык бездән беркая да китмәс, әмма зиннәтле нәрсәгә әверелер», – дип саный. Компания юнь бәягә мамык эзләп, Кытайдан Бангладешка барып караган, аннан соң Үзбәкстанга килгән. Мамык бәясе долларда 70 процентка үскән. Рясова: «Өч футболка урынына берне сатып алырбыз», – дип юата.

Владимир Путин бәяләр үсешендә Россиягә каршы кертелгән санкцияләрне гаепли. «Уңыш тыйнаграк булыр, ә бәяләр югарыга үрмәләр», – ди ул. Әмма Вашингтоннан ашлык экспорты бәрабәренә санкцияләр алынмаячагын әйтәләр. Россия дә үз чиратында авырттыргыч җавап адымнары ясарга тырыша. Көнбатышның безгә микроэлектроника кертүгә чикләүләренә каршы инерт газлар (шул исәптән неонның да) экспортын туктату белән яный. Болар ярымүткәргечләр һәм микросхемалар җитештерү өчен кирәк. Инерт газлар базарында Россия өлеше – 30 процент.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

УРЫНЫ ДА, ҖЫРЫ ДА БУЛАЧАК

tatarstan.ru

Якын киләчәктә Казанда рус фольклор үзәге белән Пушкин скверы пәйда булырга мөмкин. Рус милли-мәдәни җәмгыяте активистлары Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда шундый тәкъдим җиткерде. Очрашу Рус теле көне һәм бөек шагыйрь Александр Пушкинның тууына 223 ел тулуга багышланган бәйрәм чаралары кысасында узды.

Аңа кадәр Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев белән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Пушкин һәйкәленә чәчәкләр салды. Бөек шагыйрьнең исеме Рус милли-мәдәни җәмгыяте активистлары белән очрашуда да еш телгә алынды. Аерым алганда, җәмгыять рәисе Ирина Александровская Казанда Пушкин исемендәге сквер булдырырга тәкъдим итте. Моннан тыш, Аракчино бистәсендә юл киңәйтү аркасында, Пушкин һәйкәленең башка урынга күчереләчәген дә хәбәр итте ул. Хәзер аның кайда урнашачагын тәгаенләргә кирәк.

Ирина Александровская, Татарстанда рус теле комиссиясе оештыру турында Указ имзалавы өчен Президентка рәхмәт әйтте. Җәмгыять рәисе 2023 елда Казанда «Россия җыры» фестивале дә оештырырга тәкъдим итте. Рөстәм Миңнеханов бу фикерне хуплады. Әлеге фестивальне оештыру ягын кайгыртырга кушты ул. Татарстан Президенты рус милли-мәдәни җәмгыяте тарафыннан оештырылган «Татарстан музейларында рус коллекциясе» проектын, алар тарафыннан чыгарылган басмаларны алга таба да танытырга кирәклеген искәртте.

– Рус теле – безнең барыбызның да туган теле. Кайда гына булсак та, без аны белергә, танытырга тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов җәмгыять активистлары белән аралашу барышында. – Сез – үзенә күрә волонтер һәм энтузиастлар. Эшегездә үзегез кебек үк битараф булмаганнарга таянасыз.

Ирина Александровская, форсаттан файдаланып, Казанда ачылачак рус фольклор үзәге өчен бина табарга кирәклеген дә искәртте. Рөстәм Миңнеханов ул шәһәр үзәгендә урнашса яхшырак булачак дигән фикердә. «Болай эшләгәндә анда балаларны да җәлеп итеп булыр, ул туристлар арасында да зур кызыксыну уятыр иде», – диде Президент.

Рөстәм Миңнеханов, республика җитәкчелеге Рус милли-мәдәни җәмгыяте активистлары җиткергән барлык тәкъдим, проектларны да тормышка ашырырга ярдәм итәчәк, дип ышандырды. «Сезнең хезмәтегез бик кирәк. Без бу эшнең нәтиҗәләрен дә күрәбез. Сезгә уңышлар телим. Без сезгә һәрчак ярдәм итәчәкбез», – диде Президент.

Бәйрәм уңаеннан оештырылган төп тантана Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында узды. Анда Рөстәм Миңнеханов рус мәдәнияте байлыгын саклап калу һәм арттыру буенча кирәкле адымнарның дәүләт программаларында да чагылуын искәртте. Мисал өчен, республикада 16 ел дәвамында «Татарстанда рус теле» программасы эшли. Моннан тыш, ел саен дистәләгән рус этномәдәни проектлары да тормышка ашырыла.

– Рухи мирасны саклау эшенә битараф булмаган һәм зур өлеш керткән барлык кешеләргә, беренче чиратта мөгаллимнәргә, мәдәният хезмәткәрләренә һәм җәмәгатьчелек вәкилләренә чын күңелдән рәхмәтемне җиткерәм. Татарстанның Рус милли-мәдәни җәмгыятенең 10 еллык эшчәнлеген аерым билгеләп үтәсем килә. Бүген активистлар белән очрашуда без күп кенә актуаль мәсьәләләр буенча фикер алыштык, бурычлар билгеләдек, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Республика җитәкчесе рус телен һәм рус мәдәниятен популярлаштыруның Россия халыкларының мәдәни мирасы елында аерым әһәмияткә ия булуын искәртте. Май аенда Татарстан Президенты каршындагы Рус теле буенча комиссия оештырылуын искә төшерде ул. «Телләр, традицияләр һәм мәдәният төрлелеге – Россиянең зур байлыгы. Без күпмилләтле җәмгыятебезнең нигезен тәшкил итүче барлык халыкларның рухи кыйммәтләрен һәм үзенчәлекләрен саклап калырга тиеш», – диде Рөстәм Миңнеханов.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Халыклар арасындагы дуслыкны һәм конфессиара үзара аңлашуны ныгытуга юнәлдерелгән актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе **Сәфәров** Әсгат Әхмәт улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» III дәрәҗә ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Икътисад һәм финанс өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен «АК БАРС» акционерлык коммерцияле банкы (гавами акционерлык җәмгыяте) идарәсе рәисе **Гәрәев** Зөфәр Фәнил улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Дуслык ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Халык сәламәтлеген саклау эшенә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Лицензияләү идарәсенең фармация эшчәнлеге һәм наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм прекурсорлары әйләнеше буенча, составында наркотик матдәләр булган үсемлекләр үстерү белән бәйле эшчәнлекләрне лицензияләү бүлеге башлыгы **Вилданова** Лилия Газиз кызы; «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор А.Г. Ге исемендәге Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы – «Түбән Кама тире-венерология диспансеры» баш табибы **Карпов** Александр Анатольевич; сәламәтлек саклау өлкәсенә квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Буа медицина училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Гыймадиев** Рамил Федорович; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм сәнәгать комплексына квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен «П.В. Дементьев исемендәге Казан авиация-техник көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Җәләлов** Илгиз Ирек улы; республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Динамо» олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе тренеры **Ибраһимов** Сәгыйть Габдерәүф улы; илебез приборлар төзү тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Дәүләт гамәли оптика институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыятенең сынау заводы җыю-радиомонтаж цехының оптик-механигы **Козлов** Владимир Александрович; рус халкының рухи-әхлакый һәм мәдәни традицияләрен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «А.С. Пушкин исемендәге мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең «Коляда» фольклор-этнография ансамбле җитәкчесе, «Казанның Рус милли-мәдәни берләшмәсе» җирле иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Кузьмина** Нина Петровна; финанс-икътисади эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе баш бухгалтеры **Садыйкова** Әлфия Салих кызы; җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Электросоединитель» акционерлык җәмгыяте баш инженеры **Усманов** Рамил Надыйр улы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Рамай» фермерлык хуҗалыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Хәйретдинов** Фәрит Нәфигулла улы; «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе – Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты агробиология тикшеренүләре бүлеге баш фәнни хезмәткәре **Шакиров** Шамил Касыйм улы; мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы белән нәтиҗәле хезмәттәшлеге һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Башкорт дәүләт университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе фән-инновация идарәсенең фәнни-тикшеренү секторы баш фәнни хезмәткәре **Йосыпов** Касыйм Назиф улы **Татарстан Республикасының** «**Фидакарь хезмәт өчен**» **медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе оркестры артисты **Абдуллин** Рафаэль Илдар улына; «Мизгел» бию театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең бию коллективы артисты **Ишбулатова** Алинә Шамил кызына; «Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең бию ансамбле балет артисты **Калашова** Миләүшә Фердинанд кызына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Казан шәһәренең «Яшьлек» мәдәният сарае» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директорының иҗат эше буенча урынбасары **Волков** Айрат Илһам улына; Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Авылара үзәк китапханә» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең үзәк китапханә баш китапханәчесе **Ефимова** Надежда Дмитриевнага; «И.В. Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директорының җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча урынбасары **Иванова** Татьяна Юрьевнага; Казан шәһәренең «В.И. Ленин исемендәге мәдәният-ял итү комплексы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры **Нигъмәтуллина** Зөһрә Нурулла кызына; Казан шәһәренең «Полимер» мәдәният йорты» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры **Перелыгин** Денис Николаевичка; Казан шәһәренең «8 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең фортепиано классы укытучысы **Рәхмәтуллина** Венера Рәфхәт кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ИРТӘН ЙӨРҮ КУРКЫНЫЧ

Хәерле юл!

Юл фаҗигаләрендә иң күп үлем-китем очраклары төнге сәгать бердән иртәнге җидегә кадәр күзәтелә. Россия Эчке эшләр министрлыгының юл хәрәкәте куркынычсызлыгы фәнни үзәге белгечләре, узган ел юлларда күзәтелгән вазгыятькә анализ ясаганнан соң, шундый нәтиҗәгә килгән.

Иң күп юл фаҗигаләре кичке сәгать биш белән сигез аралыгында теркәлә, ди белгечләр. Барлык аварияләрнең чиреге нәкъ менә шушы чорга туры килә. Узган ел тәүлекнең шушы аралыгында теркәлгән юл фаҗигаләрендә зыян күргән һәр 100 кешенең 14е үлгән. Юл һәлакәтләре китереп чыгарган машина йөртүчеләрнең яше 25–49 яшь аралыгында тирбәлә, ди белгечләр. Ни гаҗәп, хатын-кыз машина йөртүчеләр юл фаҗигаләренә сирәгрәк очрый икән. Белгечләр моны рульдә йөргән гүзәл затларның азрак булуы белән аңлата.

Узган ел Россия юлларында машина белән юл кырыена төшеп китү, туктап торган машинага килеп бәрелү, ЮХИДИ инспекторы, юл төзекләндергән эшчеләрне бәрдерү очраклары да арткан. Исерек машина йөртүчеләр гаебе белән 11616 юл һәлакәте теркәлгән. Аларда 3445 кешенең гомере өзелгән. Узган ел теркәлгән һәр ун юл фаҗигасенең тугызы кагыйдә бозган машина йөртүчеләр гаебе белән килеп чыккан. Аварияләрнең өчтән бере юлларның төзек булмавы, аларның тиешле таләпләргә туры килмәве аркасында килеп чыккан.

Җәйге чорда, бигрәк тә челләдә юлдагы аварияләр саны бермә-бер артырга мөмкин дип кисәтә психологлар. Казан дәүләт медицина университеты мөгаллиме, филология фәннәре кандидаты, клиник психолог Эльмира Миассарова сүзләренә караганда, чамадан тыш эссе көннәрдә баш миендәге кан әйләнеше бозыла.

– Баш миенә һава җитми башлый. Бу, үз чиратында, кешенең психик халәтенә, зиһененә дә йогынты ясый. Нәтиҗәдә кеше таркауга әйләнә. Игътибарны туплау кыенлаша. Әйләнә-тирәдә барган хәлләрне кабул итү рәвеше дә үзгәрә. Андый чакта кеше еш кына каршында торган әйберләрне генә күрә, тирә-яктагы әйберләргә, вакыйгаларга игътибар итми башлый. Шуңа күрә юлдагы һәлакәтләрнең эсселек аркасында килеп чыгуы да бик мөмкин, – ди ул.

Белгеч сүзләренә караганда, җирнең геомагнит фонында үзгәрешләр барганда да кеше игътибарсызга әйләнә. Һава торышындагы үзгәрешләргә сизгер кешеләр бу тирбәнешләргә аеруча тиз бирешә икән. «Җәйге челләдә юл һәлакәтенә очрамас өчен машина йөртүчеләр гади генә кагыйдәләрне истә тотсын иде, – ди Эльвира Миассарова. – Юлга чыгар алдыннан, иң беренче чиратта, йокыгызны туйдырыгыз. Кул астында эчәргә һәрчак чиста су булсын. Юлда барганда, туктап, ял итәргә дә онытмагыз. Моның өчен машинагызда кечкенә генә мендәрчек йөрсен. Ерак юлга чыкканда яныгызда сезне алыштырып, ял иттереп алучы кеше булса да яхшы. Бик нык борчылганда, зур стресс кичергәндә рульгә утырмавың хәерле. Юлга чыгар алдыннан составында игътибарны тупларга комачау иткән матдәләр булган дарулар эчүдән дә тыелыгыз. Моның өчен даруның инструкциясен яхшылап укырга кирәк. Анда бу хакта кисәтелгән була».

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТАТАРСТАН ЮЛЛАРЫНДАГЫ КУРКЫНЫЧ САННАР

	2021 елның 5 ае	2022 елның 5 ае	арту/кимү
Аварияләр	1284	1161	-123
Һәлак булучылар	87	105	+18
Имгәнүчеләр	1591	1438	-153

ЗЕЛЕНОВ МИРАСЫ

Шәхес

Май ахырында Түбән Кама халкы Татарстан, Россия күләмендә танылган шәхес – республиканың шиннар сәнәгатенә нигез салучы, «Түбән Кама шин» җәмгыятенең беренче генераль директоры, шәһәрнең мактаулы гражданины Николай Александрович Зеленовны искә алды. Әгәр исән булса, аңа 90 яшь тулган булыр иде...

Түбән Кама

Ул шундый кеше иде

Николай Зеленовны искә алу аның каберенә чәчәкләр салудан башланды. Аннан соң ул яшәгән йорт диварына истәлек тактасы куелды, Халык иҗаты йортында тормыш һәм хезмәт юлына багышланган фотокүргәзмә ачылды, аның турында фильм күрсәтелде. Шушында ук Николай Александровичның шәхси әйберләрен дә күрергә мөмкин иде. Алар аны күпкырлы талант иясе буларак ача. Бу көнне Зеленов турында истәлекләр яңарды, аның адресына сагыну хисләре белән сугарылган җылы сүзләр әйтелде.

Кем ул Николай Зеленов? Аның биографиясе Түбән Кама шәһәре, химия комбинаты һәм шин заводы төзелешендә беренчеләр сафында торган, соңыннан хезмәт коллективын туплаган, озак еллар җитәкчелек иткән шәхесләрнеке белән аваздаш.

– Николай Александрович – легендар кеше! Ул – үзен завод һәм шәһәр төзелешенә, хезмәткәрләр һәм аларның гаиләләре өчен уңайлы яшәү шартлары тудыруга багышлаган кеше. Аның исеме завод, шәһәр, республика, илебез тарихына язылды. Шинчылар Николай Александровичны онытмый һәм онытмас, – ди «Татнефть-Нефтехим» идарәче компаниясе директоры, KAMA TYRES шин комплексы җитәкчесе Гүзәл Хәбетдинова.

38 яшьлек «генерал»

Ул 1932 елның 28 маенда Горький өлкәсенең Лысково шәһәрендә туа. Мәскәү химия технологиясе институтында белем ала. Хезмәт юлын Воронеж шиннар җитештерү заводында мастер сыйфатында башлаган егет хезмәт баскычы буенча заводның баш инженер урынбасары дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. 1971 елның июнендә шиннар җитештерү өлкәсендә зур тәҗрибә туплаган Николай Зеленовны Чулман елгасы буенда «баш калкыта» башлаган Түбән Кама шәһәренә юллыйлар. Берничә көн элек кенә 38 яше тулган яшь белгеч шушы шәһәрдә төзелергә тиешле шиннар җитештерү заводына директор итеп билгеләнә. Гадәттә, мондый гаять зур җаваплы вазыйфага күп еллар хезмәт итеп, ут-су кичкән, ил җитәкчелеге алдында абруй казанган кешене куялар. Шуңа күрә беренче казыгы гына кагылган предприятие дилбегәсен азау теше чыгып кына килүче белгечкә тоттыруга шикләнеп караучылар булмый калмый. Янәсе, сынмасмы, өметне акларм ы...

– Түбән Камага 1971 елның 5 декабрендә килдем. Икенче көнне үк төзелә торган заводка юл алдым. Җитәкче урынында юк, көтеп торырга туры килде. Биш минут үттеме икән, чәчен ул чактагы мода буенча кистергән яшь кенә бер ир-ат килеп керде һәм: «Сез мине көтәсезме?» – дип сорады. Бик ышанычлы тавыш белән: «Сезне түгел», – дим. «Юк, сез мине көтәсез», – диде дә кабинетына таба юнәлде. Аның артыннан секретарь кереп китте һәм кире чыгып: «Керегез», – диде. Кабинетта әле генә минем белән сөйләшкән ир-атны күргәч, кыен булып китте. Чөнки директорны чал чәчле, олы яшьтәге ир-ат дип уйлый идем, – дип искә ала заводның үзәк лабораториясенә эшкә урнашкан көнен Надежда Бурнаева.

Йөк шиннары заводы сафка басканчы ук, 1973 елда беренче автокамера «пешерелә». Түбән Кама шиннары КамАЗ, УАЗ, ВАЗ, ИжАвто, шулай ук илнең башка автомобиль заводларына озатыла. 1980 нче еллар ахырына Түбән Кама шин заводы илдә шиннар җитештерелә торган иң алдынгы предприятиеләрнең берсенә әйләнә. Түбән Кама шиннарын кулланучылар исемлеге елдан-ел арта. Һәм монда, әлбәттә, Николай Александровичның өлеше бәяләп бетергесез.

Зеленов мәктәбе

Николай Зеленов күпләр өчен җитәкче генә түгел, ә остаз, укытучы була. Укучылары, аның юлын дәвам итеп, алга таба үзләре дә югары вазыйфаларга билгеләнә, алар җитәкләгән коллектив югары хезмәт күрсәткечләренә ирешә.

«Түбән Кама шин» акционерлык җәмгыятенең элекке генераль директоры Радик Ильясов истәлегеннән:

– Мин – «Зеленов мәктәбе»н узган кеше. Ул миңа генераль директор дилбегәсен тапшырды, мин аны 14 ел үз кулымда тоттым. Николай Александрович белән еш очраштык, чөнки остазымның төпле фикере, киңәшенә мохтаҗ идем. Узган гасырның 90 нчы елларындагы икътисади кризис вакытында төшенкелеккә бирелмәскә өндәде. «Без җиңеп чыгарбыз. Бу – су болганчыкланганда хасил була торган күбек. Вакыт үтәр, су тынар һәм чистарыр», – дигәне бүгенгедәй исемдә. Әйе, аңа киләчәкне күзаллау сыйфаты хас иде.

Гаҗәеп дәрәҗәдә кешелекле. «Ярдәм сорап килүчегә «юк» дияргә ашыкма, башта үзеңне аның урынына куеп кара», – дип әйтә иде. Мин аның тавыш күтәреп сөйләшкәнен, кычкырганын хәтерләмим. Шул ук вакытта кырыс та булды. Бер-беребезгә ышаныч белдергән команда булып эшләргә өйрәтте. Аның ышанычын акларга тырышып эшләдек.

Шинчы булу тәкъдиренә язылган

Массакүләм шиннар заводының элекке директоры Мөнәвәр Әюпов әнә шулай ди. Моңа дәлиле: Николай Зеленов Советлар Союзында беренче шин заводы сафка баскан елны дөньяга килә. Күрәсең, шинчы булу язмыш дәфтәренә язылган.

– Николай Зеленов тарихка заводның беренче казыгын каккан, куллануга тапшырган, кыска гына вакыт эчендә ил күләмендә танытакан бердәнбер директор буларак кереп калыр. Һәркайда һәм һәркайчан сүзе үтте. Шуның белән абруйлы булды. Аны төрле даирә җитәкчеләр ихтирам итте. Өч дистә елга якын шин заводының алыштыргысыз директоры булды.

Аның белән танышлыгыбыз 1976 елда башланды. 1983 елда мине массакүләм шиннар заводы директоры итеп билгеләделәр. Әлеге вазыйфада 27 ел эшләдем. Шушы вакыт эчендә предприятиедә өч зур үзгәртеп кору узды. Шуның беренчесе 1980 нче еллар уртасына туры килде. Анысы да Николай Александровичның тырышлыгы, үҗәтлеге белән. Чөнки СССР нефть эшкәртү һәм нефть сәнәгате министрын чит илнең технологик җиһазларын Түбән Кама шин заводына кайтартырга нәкъ менә ул күндерә. Югыйсә алар башка завод өчен планлаштырылган була.

Аның бер сыйфаты – бөтен авырлыкны үз өстенә алырга тырышу. Кәефе төшенке булганда да, сер бирмәде, читләргә сиздермәде. Ә бит заводта төрле ситуацияләр булды. Ул аларның һәрберсен йөрәге аша үткәргәндер...

Чын җитәкче булып туган

Николай Зеленов турындагы истәлекләр арасында үзе дә бакыйлыкка күчкән Рәшит Маликов хатирәләренә юлыктым. Ул аның персонал белән идарә итү буенча урынбасары булып эшләгән.

– Җитәкче булырга өйрәнеп булмый, җитәкче булып туарга кирәктер. Николай Александровичка асыл сыйфатлар якты дөньяга килгәндә үк мулдан бирелгәндер кебек. Ул хезмәткәрләрнең хәл-әхвәлләре белән кызыксынып торды. Һәр атнаның дүшәмбесендә шинчыларны шәхси сораулар буенча кабул итте. Нинди генә гозер белән кермиләр иде аның янына! Шулай да күбесен торак мәсьәләсе борчый. Шуңа да ул шәһәрдә торак йортлар төзелешенә ярдәм итәргә тырышты. Гомумән, социаль объектлар төзүдә катнашасы килде. Тик теләк белән мөмкинлекнең тәңгәл килүе дә мөһим бит. Шулай да ул юлларын таба белде.

Николай Зеленов 2019 елның 6 февралендә арабыздан мәңгелеккә китте. Аның буыннар чылбыры буенча күчә торган эшләре калды. Чордашлары, хезмәттәшләре, шинчылар хәтерендә якты истәлеге калды. Түбән Кама тарихында җуелмас исеме калды.

Нурисә ГАБДУЛЛИНА

Түбән Кама заводына Политбюро әгъзасы, КПСС Үзәк комитеты секретаре Андрей Кириленко сәфәр кыла. 1980 ел.

Белдерү

Извещение о проведении собрания по согласованию местоположения границ земельного участка

Кадастровым инженером Галимзяновым Ф.М., являющимся членом саморегулируемой организации «Ассоциация кадастровых инженеров Поволжья» (уникальный реестровый номер 1413, номер в реестровой записи 30841 от 16.12.2016 г., 420101, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2-5, sinaf@mail.ru, (843) 514-63-63, № квалификационного аттестата 16-14-697 от 20.05.2014 г., СНИЛС 106-073-122 06), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:24:253701:794, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Орловское сельское поселение, садовое товарищество № 11 «Сатурн», участок 794, проводятся работы по уточнению местоположения границы и (или) площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Гизатуллин Марсель Радикович (Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2-5, тел.: 89030618183).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 7 июля 2022 г. в 10 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2-5, тел.: 514-63-63.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2-5, тел.: 514-63-63.

Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельного участка на местности принимаются с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2-5, тел.: 514-63-63 с 07.06.2022 г. по 07.07.2022 г.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ земельных участков с кадастровым номером 16:24:253701:793, расположенный по адресу: Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Орловское сельское поселение, садовое товарищество № 11 «Сатурн», участок 793.

16:24:253701:795, расположенный по адресу: Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Никольское сельское поселение, садовое товарищество № 11 «Сатурн», участок 795.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, нотариально заверенную доверенность на предоставление интересов юр. лица, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 года № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әтисе

БАКИРОВ Рафаэль Рөстәм улы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының бухгалтерия учеты һәм хисап бүлеге баш белгече Бакирова Мария Рафаэль кызының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан агросәнәгате ветераннар советы президиумы, заманында Алабугада район советы башкарма комитеты рәисе булып эшләгән

Илдус Әгъзам улы НИЗАМОВ

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсенең, туганнарының, таныш-белешләренең авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан халык хуҗалыгын үстерүгә зур өлеш керткән

Илдус Әгъзам улы НИЗАМОВ

вафат булу сәбәпле, Азат Гомәр улы Усманов, Марс Шәриф улы Алиев гаиләләре, мәрхүмнең туганнарының, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Дустыбыз бик мөлаем, игътибарлы, мәрхәмәтле иде. Безнең күңелләрдә ул шулай булып сакланыр да.

КАДЕРЛЕ ЯДКӘР

Нәселеңне гомер буе барларга кирәк! Нурлатта яшәүче Ләйсән Зарифуллина әнә шулай ди. Аларның гаиләсе быел «Без тарихта эзлебез» республика бәйгесендә икенче урынны яулаган. Нәсел барларга тотынулары уйламаганда гына була аларның. Улының укытучысы: «Район мәдрәсәсендә шәҗәрә бәйрәме уза. Катнашмыйсызмы?» – дип сорагач, ул ике дә уйламыйча ризалык бирә. Әнә шуннан соң эзләнүләр, табышулар китә. Алар нәселе хакында район күләмендә генә түгел, тирә-якта да беләләр хәзер.

– Әзер нәсел агачыбыз бар иде. Җыелган мәгълүмат та җитәрлек. Шуңа да катнашып карыйсым килде. Әнием ягыннан ерак бабам Фатыйх Тямаев нәселен барладым, – ди ул. – Башкортстанда яшәүче Илгиз абыебыз исә 2002 елда нәсел агачы ясый башлады. Кая гына бармады ул?! Барлык туганнарны табып, һәркайсы белән аралашып чыкты. Тамырларны белмичә яшәргә ярамый. Абыебыз бик тырышты. Буыннарны барлап, безгә дә нәсел шәҗәрәсен бүләк итте.

Мәдрәсәдә үткән бәйгедә аларның хезмәтен югары бәялиләр. Аннары аларның гаиләләрен «Без тарихта эзлебез» бәйгесенә дә чакыралар. Ләйсән бу эшкә бик җаваплы карый. Ризалык бирүен бирә, әмма эзләнүен дәвам итә. Теләге – нәселе турында тагын да күбрәк мәгълүмат табу. Түбән Норлат авылындагы музейга бара, аннары архивларда эзләнә.

– Фатыйх бабабыз 1901 елда Түбән Норлат авылында туа. Ул 17 яшендә революциядә катнаша. Инкыйлаб дулкыннары тынгач, Закирә исемле кызга өйләнә. Аларның ике балалары туа. Өченчесенә бер ятим сабыйны сыендыралар. Әмма Закирә әбинең гомере кыска була. Өч бала белән тол калган 35 яшьлек Фатыйх тагын өйләнә, Хәдичә исемле яшь кыз ала, – ди Ләйсән. – Аларның 11 балалары туа. Барлыгы 13 бала бит. Аларның һәркайсының нәсел җебен барлый башласаң, безнең буын әллә кайларга барып тоташыр иде. Әлегә мин үз әнием ягыннан биш буынымны гына таптым. Киләчәктә тукталып калмаска, тагын да күбрәк туганымны эзләргә җыенам.

ШӘҖӘРӘ

«Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының уртак проекты

Ләйсән эшне бабасы Фатыйхтан башлый. Түбән Нурлат авылындагы музейда бабасының язмышы, исәп алып барган кенәгәсе саклана икән. Сакланыр да! Үз авылы өчен күпне эшләгән кеше ул. Сугыш башлангач, Фатыйх абыйны колхоз рәисе итеп куялар. Ул рәислек эшен бик җаваплы башкара. Халыкны тыңлата, эшләтә белә. Фашистларны җиңәр өчен тылда кулдан килгәнне эшлиләр. Ул вакытларда Октябрь колхозы һәр эштә алдынгылардан була. Сугышка ярдәм йөзеннән халык акча җыеп та тапшыра. 20 мең сум акчаны Фатыйх абый Сталинга җибәрә. «Дошманны юк итәр өчен самолет төзегез», – дип яза ул хатында. Озак та үтми, Фатыйх абыйга җавап хаты килеп төшә. Сталиннан килгән бу истәлек әле дә саклана икән.

– Бәйгедә без бабайның бар тормышын театраль тамаша итеп күрсәттек. Халык чыгышыбызны яратты. Район күләмендә – беренче, зонада икенче урынны алдык. Мондый бәйгеләрдә йөреп, тәҗрибә туплыйбыз. Башкаларны күрәбез, алардан үрнәк алабыз. Чаралар уза да китә, ә менә күңелдә рәхәт хисләр кала. Әби-бабаларның рухы шатланыр кебек. Без, нәсел дәвамчылары, аларны онытмаска, безгә биргән тәрбияләрен, гаиләбезнең гореф-гадәтләрен сакларга тиеш. Бу – безнең бурыч, – ди Ләйсән.

Фатыйх бабайның Халисә исемле кызы Ләйсәннең ерак дәү әнисе була.

– Әбиебез Хәдичә бик укымышлы иде. Татар, рус, немец телләрен дә белә. Кызганыч, күпме генә сандык төпләрен актарсак та, шәхси әйберләре калмаган. Кызы Халисәдә генә бер дисбесе сакланган. Халисә әби – әниемнең әнисе. Ул бу дисбене миңа тапшырды. Без аны кадерләп саклыйбыз. Дисбебез, кадерле бер ядкәр булып, буыннан-буынга күчәр, – ди Ләйсән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ РЕМОНТ БРИГАДАСЫ
барлык төрдәге төзелеш эшләрен башкара
ЯЗГЫ ТАШЛАМАЛАР

Үзебезнең яки заказчының материалын кулланабыз.
Коймалар, терраса, фундамент, сайдинг, түбә эшләре, мунча, беседка, хуҗалык корылмалары, өй күтәрү, бүрәнәләрне алыштыру, отмостка, борыс имитациясе эшләре.
Пенсионерларга 15-20% ташлама!
Өйләрне блок-хаус белән тышлау эшләре һ.б.
Мөрәҗәгать иткән көнне үк киләбез!
тел.: 8 905 199 99 79
Реклама

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

Сабан туен көткәндә

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сөлгеләрне сөлгеләргә ялгап...

Быел Казан Сабан туе 17 июньдә – сөлге җыю бәйрәме белән башланып, 19 июньдә көрәш батырын ачыклау белән тәмамланачак.

Татарстан башкаласында узачак бәйрәмнең быелгы үзенчәлекләре турында Казан Башкарма комитетының мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов «Эшлекле дүшәмбе» вакытында сөйләде.

17 июнь. Бу көнне 11.00 сәгатьтә Казанның үзәк урамнарыннан уза торган махсус маршрут буенча, йоласына туры китереп, Сабан туена сөлге, бүләкләр җыячаклар. Сөлге җыю Камал театры янындагы мәйданда концерт программасы белән тәмамланачак.

18 июнь. 16.30 сәгатьтә Казан ипподромында традицион ат чабышлары башланачак. Барлыгы 14 чабыш булыр дип көтелә. Шулай ук бу көнне кунакларны концерт программасы һәм бүләкләр уйнату да көтә. Бәйрәм салют белән тәгәлләнәчәк.

19 июнь. Күңел ачулар Тынычлык бистәсендәге Каенлык, Дәрвишләр бистәсендә һәм Аккош күлендә дәвам итәчәк. Бәйрәм чаралары 9.30 сәгатьтә башлана.

Беренче мәйданчыктагы бәйрәм татар яшьләренең борынгы йоласы – утырма белән башланып китәчәк. Монда шулай ук татар эстрадасы йолдызларының чыгышы да көтелә.

Дәрвишләр бистәсе һәм Аккош күлендә дә танылган җырчылар чыгыш ясаячак. Татарстанның иң көчле көрәшчеләре дә шушы көнне ачыкланачак. Төп батырга тәкә һәм квадроцикл тапшырылачак.

Сабан туе мәйданчыклары 16.00 сәгатькә кадәр эшләячәк.

НИЧЕК БАРАСЫ?

Кунаклар өчен махсус автобус маршрутлары оештырылачак, шәһәрдә өлешчә юл хәрәкәте схемасы үзгәрәчәк.

Тынычлык бистәсендәге Каенлыкка махсус автобуска дүрт тукталыштан утырып китәргә мөмкин. Болар – «Җиңү проспекты станциясе», «10 нчы микрорайон», «Филармония концертлар залы» һәм «Глазунов урамы» (Теплоконтроль) тукталышлары. Моннан тыш, Каенлыктагы Сабан туена «Казан-1» станциясеннән 23 нче һәм 56 нчы номерлы электр поездында килергә мөмкин булачак.

Аккош күленә Компрессор заводы һәм «Мега» сәүдә үзәге яныннан узачак автобусларда, шулай ук 1, 25, 24, 60, 84, 91 нче номерлы шәһәр автобусларында барып җитәргә мөмкин булачак.

ЧАЛЛЫ

Чаллыда да бер көн белән генә чикләнергә уйламыйлар. 17 июньдә мөмкинлекләре чиклеләр өчен бәйрәм уздырырга җыеналар. Икенче көнне исә кунакларны «Яр буе» паркында көтәләр. Кичен монда Татарстанның халык артисты Гүзәл Уразова чыгыш ясаячак.

ТҮБӘН КАМА

Сабантуй инде бу атнада – 11 июньдә узачак. Бәйрәм чаралары 9.00 сәгатьтә башлана. Түбән Кама Сабан туеның үзенчәлеге – районның 15 авыл җирлеге вәкилләре кунакларга «Минем авылым» дип аталган тематик интерактив мәйданчыкны тәкъдим итәчәк. Халыкның күңелен Фирдүс Тямаев белән Илсөя Бәдретдинова күрәчәк.

* * *

Сабантуйларны Башкортстанның 18 районында уздырырга өлгергәннәр инде. 4 июньдә Самара халкы да бәйрәм иткән. 5 июньдә исә милли бәйрәмне Новосибирскида яшәүче милләттәшләребез дә үткәргән.

Алда әле бәйрәмнәр тагы да көтелә. Исегезгә төшерәбез: Татарстан авылларында, район үзәкләрендә бәйрәм 11–13 июньдә узачак. 17–18 июньдә Ульян өлкәсендә – Федераль Сабан туе, 2 июльдә Мордовиянең Аксен авылында Бөтенроссия татар авыллары Сабан туе үткәреләчәк.

СЫЙЛЫ БӘЙРӘМ

ӘГЕРҖЕ РАЙОНЫНЫҢ КАДРӘК АВЫЛЫНДА РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ СЕМЫК УЗДЫ

Әгерҗе

Семык – мариларның иң яраткан бәйрәмнәренең берсе. Ул җәйне каршы алуны да, якты дөньядан киткәннәрне хөрмәтләүне дә чагылдыра. Мариларның җир эшкәртү, авыл хуҗалыгы, гаилә мөнәсәбәтләре һәм башкалар белән бәйле бик күп традицияләрен һәм йолаларын үз эченә ала ул.

agryz-rt.ru

Кадрәк авылында узган Семык бәйрәмендә көне буе диярлек тоташтан яңгыр яуды. Әмма ул бәйрәмнең ямен дә бетермәде, халыкның кәефен дә төшермәде. Семык булачак мәйданга халык иртән иртүк килә башлады.

– Узган ел Семык безнең районда гөрләгән иде. Бирегә «Ший памаш» фольклор халык ансамбле вәкилләре белән бергәләп килдек. Элек ансамбльгә без дә йөрдек. Хәзер урыныбызны яшьләргә бирдек, – диделәр Актаныш районыннан килгән Галина Михайлова белән Тамара Солтангалина. – Безгә һава торышының нинди булуы мөһим түгел. Яңгыр яуганга артык борчылмыйбыз. Ходай Тәгалә үзе белеп бирә ул.

Кунаклар Семык аллеясына агач та утырттылар.

– Бездән матур истәлек калсын әле, – диделәр Балтач районы Улисьял авылыннан килгән делегация вәкилләре.

Шул рәвешле, бәйрәмгә бер-бер артлы республиканың Актаныш, Арча, Балтач, Алабуга, Кукмара, Мамадыш, Минзәлә, Мөслим районнарыннан, Казан, Түбән Кама, Чаллыдан, Мари Иле, Удмуртия, Башкортстаннан, Свердлау өлкәсеннән, Алтай краеннан делегацияләр килде. Әлбәттә, бәйрәмне кабул итүче Әгерҗе районы делегациясе сан ягыннан иң зурлардан булгандыр.

Кунаклар мари, рус, татар, удмурт, чуаш ишегалларын кереп күрде. Әгерҗе районының тарихы һәм бүгенгесе белән танышты. Шунда ук мариларның ачык һавада урын алган мичтә пешерелгән милли ризыклары – «коман мелна»дан (безнеңчә әйтсәк, белен) да авыз итәргә була иде. Кунаклар Чирмешән районыннан килгән чуаш вәкилләре янында тукталып, үзенчәлекле мастер-классны күзәттеләр. Асылы бик тә гади: махсус зур иләк ярдәмендә бодайны иләп, юып, киптереп, ярма ясап, шунда ук ботка пешерәләр. Табигый ризыктан авыз итүчеләр дә күп булды.

Бәйрәмне башлап җибәрү өчен сәхнәгә Татарстан мариларының милли-мәдәни автономия җитәкчесе, республиканың баш карты (рухи җитәкчесе) Олег Третьяков күтәрелде. Бәйрәм әләмен Кадрәкнең хөрмәтле кешеләре – Виталий Савельев, Анна Асылбаева һәм «Кадрек сем» ансамбле вәкилләре күтәрде. Бәйрәмнең рәсми өлешен район башлыгы Азат Вәлиев ачты.

– Әгерҗе районында төрле милләт һәм дин вәкилләре дус һәм тату гомер кичерә. Шулар арасында хезмәт сөючән мари халкының да лаеклы урыны бар. Алар халык хәтерен, матур традицияләрен, җыр-биюләрен саклап яшиләр, спорт өлкәсендә зур уңышларга ирешәләр, – диде район башлыгы. – Ә бүгенге яңгырга иген үстерүчеләр бары тик сөенергә тиеш. Җылы җәйге яңгыр – яхшы уңыш нигезе ул.

Премьер-министр урынбасары Роман Шәйхетдинов – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның, Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов парламент Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның котлау сүзләрен җиткерде.

– Семык бәйрәме республикабызда 1990 елдан бирле зурлап билгеләп үтелә. Ә быелгысы Халык сәнгате һәм мәдәни мирасны саклау елында узуы белән үзенчәлекле. Бүген һәркайсыбызның үзен күпмилләтле бердәм Россия мәдәниятенең һәм халык тарихының бер өлеше итеп тою мөмкинлеге бар, – диде Роман Шәйхетдинов.

– Әгерҗе районы – Татарстанның иң матур төбәкләренең берсе. Бирөдә иң зур елгалар, урманнар урнашкан. Мариларның балы – иң тәмлесе. Марилар – хезмәт сөючән халык. Һәр халык менә шулай телен, традицияләрен сакласын иде. Бу шулай булсын өчен барыбыз да тырышырга тиеш, – дип теләде Татарстан Халыклар дуслыгы йорты директоры Ирек Шәрипов.

«Семык бәйрәме – халык рухы хәзинәсе» дип аталган театральләштерелгән күренеш бәйрәмнең иң матур һәм иң истәлекле өлеше булды. Ул Кадрәк авылының тарихын бәян итеп кенә калмыйча, чыгыш ясаучылар тамашачыга мари халкының традицияләрен һәм көнкүрешен, аларга хас табигатьне ярату, киң күңеллелек, кунакчыллык кебек сыйфатларын да күрсәтте.

Бәйрәмгә җыелган халыкның күңелен республика районнарыннан, Россия төбәкләреннән килгән иҗат коллективлары күрде. Аларны тамаша кылганда да, «Мари Иле» дәүләт бию ансамбленең дәртле, матур чыгышларын караганда да халык рәхәтләнеп биеде, кушылып җырлады. Михаил Веселов һәм Лилия Петухова иҗат коллективы катнашындагы күңел ачу программасы бәйрәм кичено нокта куйды.

Көнозын яуган яңгыр спорт ярышларын уздыруга да киртә була алмады. Үзләрен чаңгыда узышу, гер күтәрү, утын кисү, чүлмәк вату кебек ярышларда сынаучылар булды. ГТО нормаларын үтәү мәйданчыгы эшләде. Шулай да иң үҗәтләре, чыдамнары волейболчылар булгандыр, мөгаен. Алты команда арасында ярыш бик кызу барды. Нәтиҗәдә беренче-өченче урыннарны Мадык, Сарсак-Омга, Тирсә волейболчылары алды.

Семык бәйрәме июнь аена билгеләнсә дә, марилар аңа узган ел ук әзерләнә башладылар. Уртак тырышлык белән бер-бер артлы бәйрәм капкасы, җил тегермәне, кунакчыл мари ишегалды, хәтта күперле ясалма күл барлыкка килде. Бергәләп юлларны тәртипкә китерделәр, эскәмияләр, өстәлләр, кече сәхнәләр, балалар мәйданчыгы ясадылар. Соңгы вакытларда, йокыларын да онытып, бергәләп милли ризыклар әзерләделәр. Бәйрәм көнне казаннарда ризык пеште, чәй кайнады. Бердәмлек, тырышлык, кунакчыллык бәйрәме булды ул. Киләсе елда да республикакүләм Семык Әгерҗе районында узачак. Бу юлы – Бима авыл җирлегенә караган Пеләмеш авылында.

Дания АБЗАЛИЕВА

БИЕГӘН КЕШЕ БАЙ БУЛА!..

КАЗАН ХАЛКЫН «ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ» ОСТАХАНӘЛӘРЕНӘ ЧАКЫРАЛАР

Халык биюләрен сәхнәдән генә кем дә карап утыра ала ул. Бер сәгать буе «Ярмәк вагы»на басып кара син! «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проектының җәйге остаханәләре нәкъ менә шул биюне өйрәнүдән башланды. 500ләп кеше Кабан күле буендагы агач идәннәрнең ныклыгын тикшерде.

kzn.ru

Узган җәйдә «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проекты кысасында 14 чара узган. Аларда барлыгы 550 кеше катнашкан. Очрашулар Кабан күле буеннан тыш, «Ак чәчәкләр» һәм Фучик бульварларында, Горький һәм Урицкий паркларында, «Черек күл»дә узган. Проектның юнәлешләре арасында йога, сулау практикалары, спорт, биюләр бар.

Әллә һава торышының җайлануы, әллә спортлы-иҗатлы «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проектының популярлыгы, әллә халыкның биюгә сусавы шулай тәэсир иткән – болай да кеше белән «кайнап» торган Кабан буена халык агылды да агылды. Яңа гына тәпи киткән сабыйлардан башлап, таякка таянган әби-бабайларга кадәр бар иде анда.

Әйткәнебезчә, ул кичне теләгән һәркемне «Ярмәк вагы» халык биюенә өйрәттеләр. Бу биюнең тарихы болайрак: Самара өлкәсенең Ярмәк авылы егетләре армиягә китәр алдыннан җыелышып күңел ача торган булган. Биюләрсез дә булмаган. Ләкин гади генә бию булмаган ул. Берсе икенчесенең аяк астына чыбыркы белән суккан, икенчесе шуңа басарга тырышкан. Шул рәвешле тыпырдау килеп чыккан. Элек «Ярмәк вагы»на егетләр генә басса, тора-бара яшь кызлар да бии башлаган. Моны безгә Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле артисты Владислав Уткин сөйләде. Алар бу биюне Самарадагы «Ак каен» ансамбле җитәкчесе Наил Галимуллиннан отып калган икән.

Шәһәр халкы өчен бию дәресен Владислав белән берләттән педагог-хореограф Сәидә Миңнебаева, фламенко биюе остасы Гөлсинә Галимуллина, «Казан» бию ансамбле солисты Рамазан Җамалетдинов үткәрде. «Татар биюен бер урында тыпырдау белән чикләнә дип уйлый күрмәсеннәр иде», – ди биючеләр. Шуңа да халык биюенең үзенчәлекләре, сез һәм без белмәгән хәрәкәтләре белән таныштырырга ниятлиләр.

Казан башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, әлеге проектны башлап җибәрүче Гүзәл Сәгыйтова әйтмешли, татар биюе, татар теле тантана иткән шушы кечкенә бәйрәмнең дә әһәмияте шактый. «Үзегез дә күрәсез: биючеләр дә, күзәтүчеләр дә бик күп. Димәк, халыкка бу кызык һәм кирәк. Остаханәләрдә катнашучыларның төрле яшьтә булуы да сөендерә. Өлкәннәр генә килсә, яшьләр кызыксынмый, дияр идек, яшьләр генә җыелса, шулай ук аудиториябез тар тоелыр иде. Бүгенге дәрес һәм, гомумән, бу проект татарларның биемичә яши алмавын кабат раслый», – дип сөйләде ул. Элегрәк су буйларын шау-гөр китергән кичке уеннарны «терелтергә» кирәк безгә. Гүзәл Сәгыйтова әнә шундый фикер-теләге белән дә уртаклашты. Яхшы булыр иде ул, шулай бит?

Янә «Ярмәк вагы»на әйләнеп кайтсак, җиде түгел, сигезенче кат тирне чыгара торган дәртле бию булып чыкты ул. Сәхнәдән биегәннәрен карап тору, ай-һай, ансат икән. Ә баса башласаң, туктап булмый. Арыганнарың да онытыла, кәефең дә яхшыра. Түгәрәкләнә дөньясы да. Менә шундый бию бүләк иткән безгә Самарада яшәүче милләттәшләребез.

Самара, димәктән, чарага килүчеләр арасында «Ярмәк вагы»ның шушы рәвешле яшәвен, халык арасында шулкадәр зур кызыксыну уятуын күреп, күз яшьләрен тыя алмаган бер ханым да бар иде. Самарада яшәүче Альбина Шәмсетдинова Татарстан башкаласына эшләре буенча килгән була. Ә Кабан буендагы бу чараны, гомумән, очраклы рәвештә, узып барышлый гына күреп, дөресрәге, ишетеп ала. «Кабан күле буена «Ярмәк вагы»ның көен ишетеп төштем. Шунда ук күңелем тулды, ирексездән елый башладым. Бу биюне шулкадәр оста итеп биюләрен, алай гына да түгел, халыкка өйрәтүләрен күргәч, шундый сөендем. Ярмәк авылыннан чыккан бию – Казан, татар үзәгендә! Аны шулай актуаль һәм популяр итүләре өчен мең рәхмәтле мин», – дип сөйләде ул безгә.

«Ярмәк вагы» Самара өлкәсендә бүген дә популяр икән. «Туйларда, яшь егетләрне армия сафларына озатканда, гомумән, мәҗлесләрдә әле дә биилләр аны. Ярмәкнең үзендә аеруча популяр ул. Сәхнәгә чыгып кына түгел, бар халык бергәләп бии «Ярмәк вагы»н», – диде Альбина ханым.

«Хәрәкәттә – бәрәкәт» проекты кысасындагы чаралар июньнән алып сентябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Ачык һавадагы бушлай остаханәләргә теләгән һәркем килә ала. Киләсе очрашу 15 июньдә, шулай ук Кабан күле буенда узачак. Бу юлы Камал театры артистлары чечетка биергә өйрәтәчәкләр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7057 данә
Гомуми тираж – 16016 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 279

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+